ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

7 август, 2024 ел № 35/9

«85 нче психологик-медик-социаль ярдәм күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәләрне раслау хакында

«Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы карамагындагы аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында»2019 елның 1 ноябрендәге 998 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 10 июнендәге 416 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Расларга:

1) «85 нче психологик-медик-социаль ярдәм күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә;

2) «85 нче психологик-медик-социаль ярдәм күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең гомумтармак вазыйфалары, эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә;

2. Көчен югалткан дип танырга:

1) Шәһәр Советының «Муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренең һәм хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2020 елның 6 февралендәге 36/5 номерлы Карарының 1 пунктын, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru 12.02.2020 урнаштырылган, «Челнинские известия» газетасының 2020 елның 12 февралендәге 10, «Шәһри Чаллы» газетасының 2020 елның 12 февралендәге 10 саннарында басылган;

2) Шәһәр Советының «Шәһәр Советының муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү өлкәсендәге аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 27 декабрендәге 11/7 номерлы Карарының 16 пунктын, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru 14.01.2022 урнаштырылган, «Челнинские известия» газетасының 2022 елның 19 гыйнварындагы 3, «Шәһри Чаллы» газетасының 2022 елның 19 гыйнварындагы 3 саннарында басылган;

3) Шәһәр Советының «Шәһәр Советының муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү өлкәсендәге аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 8 декабрендәге 18/7 номерлы Карарының 3 пунктын, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru 21.12.2022 урнаштырылган, «Челнинские известия» газетасының 2022 елның 21 декабрендәге 93, «Шәһри Чаллы» газетасының 2022 елның 21 декабрендәге 93 саннарында басылган;

4) Шәһәр Советының «Шәһәр Советының муниципаль оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү өлкәсендәге аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 29 мартындагы 22/7 номерлы Карарының 1 пунктын, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru 10.04.2023 урнаштырылган, «Челнинские известия» газетасының газетасының 2023 елның 5 апрелендәге 23, «Шәһри Чаллы» газетасының 2023 елның 5 апрелендәге 23 саннарында басылган;

5) Шәһәр Советының «Шәһәр Советының муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү өлкәсендәге аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 6 декабрендәге 28/7 номерлы Карарының 4 пунктын, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru 19.12.2023 урнаштырылган. «Челнинские известия» газетасының 2023 елның 8 декабрендәге 90, «Шәһри Чаллы» газетасының 2023 елның 8 декабрендәге 90 саннарында басылган.

3.Әлеге Карар рәсми басылган көненнән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 июленнән соң хасил булган хокукый мөнәсәбәтләр өчен гамәлдә дип билгеләргә.

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ